ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

«Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законны гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 14 июлендә
кабул ителде

1 статья

«Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законны гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 12 (I өлеш); 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 29 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруның аерым мәсьәләләре турында**»;

2) 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль

закон (алга таба – Федераль закон) нигезендә Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны (алга таба – даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу) оештыруның аерым мәсьәләләрен җайга сала, шулай ук даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен билгели.»;

3) 3 статьяда:

а) 1 өлештә түбәндәге эчтәлекле 3^2 пункт өстәргә:

«3^2) даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру функцияләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органын (алга таба – вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы) билгели;»;

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы:

1) даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларын эшли;

2) үз компетенциясе чикләрендә даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны планлаштыру документын эшли һәм аны гамәлгә ашыра;

3) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның дәүләт заказчысы функцияләрен башкара, дәүләт контрактын төзи һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут карталарын бирә;

4) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурсны оештыручы функцияләрен башкара, мондый конкурста катнашуга заявкаларның критерийларын бәяләү өчен шкала билгели, йөртүчеләргә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут карталарын бирә;

5) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурсны үткәрү турында хәбәрне һәм аңа кертелгән үзгәрешләрне үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру тәртибен билгели;

6) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурста катнашуга заявка рәвешен һәм әлеге заявканың эчтәлегенә (шул исәптән ачык конкурста катнашучының тәкъдимен тасвирлауга) таләпләрне билгели;

7) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның регионара һәм муниципальара маршрутларында башлангыч һәм (яисә) соңгы тукталыш

пунктлары буларак файдалану рөхсәт ителә торган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан тукталыш пунктларының исемлеген төзи;

8) Татарстан Республикасы чикләрендә уза торган даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның регионара маршруты буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган транспорт чараларының экологик характеристикаларына таләпләрне билгели;

9) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары реестрын алып бару тәртибен, аңа даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча гамәлгә ашырыла торган даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның төрен үзгәртү турында белешмәләр кертү тәртибен раслый, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары реестрын алып бара;

10) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларын билгеләү, үзгәртү, туктату тәртибен (шул исәптән юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларның шушы маршрутларны билгеләү, үзгәртү йә туктату турындагы гаризаларын карау тәртибен, шулай ук шушы маршрутларны билгеләүдән йә үзгәртүдән баш тарту өчен нигезләрне, шушы маршрутларны туктату өчен нигезләрне) раслый, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларын билгели, үзгәртә һәм туктата;

11) автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләүне гамәлгә ашыра;

12) даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә Россия Федерациясе законнары, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә үз компетенциясенә кертелгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.»;

4) 4 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4 статья. **Даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә җирле үзидарә органнарының вәкаләтләре**

Җирле үзидарә органнары даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә:

1) даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә норматив хокукый актлар кабул итәләр;

2) үз компетенциясе чикләрендә даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны планлаштыру документын әзерләү тәртибен раслыйлар, бу документны кабул итәләр һәм гамәлгә ашыралар;

3) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль заказчысы функцияләрен башкаралар, муниципаль контракт төзиләр

һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут карталарын бирәләр;

4) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурсны оештыручы функцияләрен башкаралар, мондый конкурста катнашуга заявкаларның критерийларын бәяләү өчен шкала билгелиләр, йөртүчеләргә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут карталарын бирәләр;

5) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурсны үткәрү турында хәбәрне һәм аңа кертелгән үзгәрешләрне даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутын билгеләгән вәкаләтле җирле үзидарә органының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру тәртибен билгелиләр;

6) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурста катнашуга заявка рәвешен һәм әлеге заявканың эчтәлегенә (шул исәптән ачык конкурста катнашучының тәкъдимен тасвирлауга) таләпләрне билгелиләр;

7) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрын алып бару тәртибен, аңа даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча гамәлгә ашырыла торган даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның төрен үзгәртү турында белешмәләр кертү тәртибен раслыйлар, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрын алып баралар;

8) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларын билгеләү, үзгәртү, туктату тәртибен (шул исәптән юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларның шушы маршрутларны билгеләү, үзгәртү йә туктату турындагы гаризаларын карау тәртибен, шулай ук шушы маршрутларны билгеләүдән йә үзгәртүдән баш тарту өчен нигезләрне, шушы маршрутларны туктату өчен нигезләрне) раслыйлар, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларын билгелиләр, үзгәртәләр һәм туктаталар;

9) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларында башлангыч һәм (яисә) соңгы тукталыш пунктлары буларак файдалану рөхсәт ителә торган муниципаль берәмлекләр территорияләрендә урнашкан тукталыш пунктларының исемлеген төзиләр;

10) вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органына даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларында муниципаль берәмлекләр территорияләрендә урнашкан тукталыш пунктларын билгеләү буенча тәкъдимнәр җибәрәләр;

11) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларында җайга салынмый торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүгә һәм багаж ташуга, кирәк булган очракта, таләпләр билгелиләр;

12) автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль кысаларында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләүне гамәлгә ашыралар;

13) даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә Россия Федерациясе законнары, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә үз компетенциясенә кертелгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыралар.»;

5) түбәндәге эчтәлекле 4^1 статья өстәргә:

«4^1 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары арасында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру буенча вәкаләтләрне бүлешү**

Даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының әлеге Законда каралган вәкаләтләре алар арасында «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1^2 өлешендә каралган тәртиптә бүленергә мөмкин.»;

6) 5 статьяда:

а) 7 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның тиешле маршрутлары реестрларына шушы маршрутлар турында Федераль законның 26 статьясындагы 1 өлешенең 1 – 11 пунктларында каралган белешмәләр кертелгән көннән, әлеге реестрларда шушы маршрутлар турында Федераль законның 26 статьясындагы 1 өлешенең 3 – 11 пунктларында каралган белешмәләр үзгәртелгән көннән тиешенчә билгеләнгән яисә үзгәртелгән дип санала һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның тиешле маршрутлары реестрларыннан шушы маршрутлар турында белешмәләр төшереп калдырылган көннән туктатылган дип санала.»;

б) 8 – 10 өлешләрне үз көчен югалткан дип танырга;

7) түбәндәге эчтәлекле 5^1 статья өстәргә:

«Статья 5[1]. **Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары реестрлары**

1. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары реестрын алып бару шушы маршрутларны билгеләгән вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрын алып бару шушы маршрутларны билгеләгән вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3. Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары реестрларына Федераль законның 26 статьясындагы 1 өлешендә каралган белешмәләр кертелергә тиеш. Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары реестрларына кертелгән белешмәләр (индивидуаль эшкуарның тору урыны турындагы белешмәләрдән тыш) үз вәкаләтләренә шушы реестрларны алып бару кертелгән вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының яисә вәкаләтле җирле үзидарә органының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.»;

8) 6 статьяда:

а) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

1) вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы яисә вәкаләтле җирле үзидарә органы йә башка дәүләт заказчысы яисә муниципаль заказчы тарафыннан, Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып, дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә дәүләт контракты яисә муниципаль контракт төзү юлы белән;

2) концессия килешүләре турында Россия Федерациясе законнары, дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык турында Россия Федерациясе законнары нигезендә даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру өчен шәһәр җир өсте электр транспортының транспорт чараларыннан (трамвайлардан, троллейбуслардан), тышкы чыганактан корыла торган батареядагы электр энергиясе белән хәрәкәткә китерелә торган автобуслардан (электробуслардан) файдалануны һәм аларның хәрәкәтен технологик яктан тәэмин итә торган объектларны эксплуатацияләүне күздә тоткан концессия килешүе, дәүләти-хосусый партнерлык турында килешү, муниципаль-хосусый партнерлык турында килешү төзү юлы белән, – әгәр бу даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны планлаштыру документында яисә халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең региональ комплексы планында каралган булса.»;

б) 4 өлештә «Федераль законда билгеләнгән тәртиптә үткәрелә торган ачык конкурс нәтиҗәләре буенча бирелгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

9) 7 статьяда:

а) 2 өлештә «ачык конкурс» сүзләрен «даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурс» сүзләренә алмаштырырга;

б) 6 өлешнең 1 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

10) түбәндәге эчтәлекле 7^2 статья өстәргә:

«7^2 статья. **Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның регионара һәм халыкара маршруты буенча автовокзаллар яисә автостанцияләр территорияләреннән читтә урнашкан тукталыш пунктларыннан файдалану**

1. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның регионара яисә халыкара маршруты буенча тукталыш пунктлары автовокзаллар яисә автостанцияләр территорияләрендә урнашырга тиеш. Татарстан Республикасы территориясендә башка тукталыш пунктларыннан файдалану вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының норматив хокукый актында каралган очракта рөхсәт ителә.

2. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның регионара яисә халыкара маршруты буенча автовокзал йә автостанция территориясеннән читтә урнашкан тукталыш пунктлары, әлеге статьяның 1 өлешендә каралган очракта, Автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж ташу кагыйдәләрендә билгеләнгән таләпләр нигезендә җиһазландырылган булырга тиеш. Автовокзал йә автостанция территориясеннән читтә урнашкан тукталыш пунктлары күрсәткечләрендә регионара яисә халыкара маршрут буенча мәгълүмат урнаштыру вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан оештырыла.»;

11) түбәндәге эчтәлекле 7^3 статья өстәргә:

«7^3 статья. **Даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны тоткарлыксыз гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру**

1. Даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны тоткарлыксыз гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән муниципаль берәмлекләр территорияләрендә заказ буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өчен файдаланыла торган бер үк транспорт чарасын бер ай эчендә өч тапкырдан артык җибәрү тыелган урыннар яисә алардан җибәрү вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы белән килештерелергә тиеш булган урыннар билгеләнергә мөмкин.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган транспорт чарасын җибәрүне килештерү (шул исәптән мондый килештерүдән баш тарту өчен нигезләр) вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының норматив хокукый актында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.».

2 статья

1. Әлеге Закон, бу Законның 1 статьясындагы 10 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 10 пункты 2023 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 25 июль
№ 48-ТРЗ